# ДӘРЕСЛЕК ТӨЗҮ ТЕОРИЯСЕН ҮСТЕРҮДӘ ҖИТДИ АДЫМ

Соңгы елларда вакытлы матбугатта мәктәп дәреслекләрен төзүгә караган бәхәсле мәкаләләр күп басыла. Галимнәрнең тикшерүенә караганда, хәзерге дәреслекләр заман таләбенә җавап биреп җиткермиләр, аларда укучыларның танып-белү эшчәнлеге белән идарә итү өчен кирәкле материаллар тиешле күләмдә урнаштырылмый, кайберләрендә искергән мәгълүматлар шактый, күбесендә җәмгыять тормышында һәм фәндәге үзгәрешләр искә алынмый. Дәреслекләрдә белем алуга ярдәм итми торган белешмәләр дә бар. Матбугатта бу мәсьәләләр хакында бер-берсенә капма-каршы фикерләр еш очрый. Дәреслекләрнең эчтәлеге укыту системасына куела торган яңа таләпләргә җавап бирергә тиешлеге бәхәссез. Бу — бүгенге көннең мөһим бурычларыннан берсе.

Д. Д. Зуевның Мәскәүдә «Педагогика» нәшриятында чыккан «Мәктәп дәреслеге» («Школьный учебник» [1] ) дигән монографиясе хәзерге дәреслекләрнең нинди булырга тиешлеге мәсьәләләренә багышланган, һәм ул, гомумән алганда, заман рухына туры килә.

Автор бу хезмәтендә дәреслекләр теориясендә тупланган казанышларны гомумиләштерүне һәм мәктәп дәреслекләрен камилләштерү теориясен тагын да баетуны төп бурыч итеп куйган. Ул — максатына ирешкән. Д. Зуев китабы — дәреслек теориясен һәм укыту теориясе эчтәлеген эшкәртүдә мөһим яңа башлангыч.

Монографиядә совет мәктәбендә дәреслек теориясенең үсеше шактый тирән анализлана, аның төп юнәлешләре билгеләнә, текстларны сайлауга куела торган таләпләр күрсәтелә, дәреслекләргә анализ ясау һәм аңа бәя бирү методикасы бәян ителә.

Автор үзенең хезмәтендә мәктәп дәреслеге үти торган функцияләр системасын (информация бирү, белемне системалаштыру, ныгыту, үз белемеңне күтәрү, кызыксыну уяту, координацияләү, акыл үсешенә ярдәм итү, тәрбияләү) эшкәрткән, һәм ул функцияләр җентекләп тәфсир ителгән.

Галим гамәлдәге укыту программалары нигезендә тезелгән дәреслекләрдәге

[1] Зуев Д. Д. Школьный учебник. М., «Педагогика», 1983.

фәнни материалның укучылар үзләштерергә тиешле төп чыганак булуын ышандырырлык итеп дәлилли. Фәнни белемнәр турындагы белешмәләрнең дәреслеккә укучыларның яшь үзенчәлекләрен искә алып кертелергә тиешлеген әйтә.

Китапта билгеләп үтелгәнчә, дәреслек укучы интеллекты үсешенә ярдәм итәргә тиеш. Д. Д. Зуев дәреслеккә урнаштырылган сорау һәм биремнәрнең зур әһәмияткә ия булуын күрсәтә, сорау һәм биремнәргә таянып, укучыларның фикер эшчәнлеген стимуллаштырырга, аларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, дикъкатен үстерергә, мөстәкыйль фикерләү күнекмәләре формалаштырырга, ягъни программада билгеләнгән күләмдә белем һәм күнекмәләрне үзләштерү процессын бик әйбәт оештырырга мөмкин икәнлеген әйтә. Галим шушы фикердән чыгып эш итә. Шуңа күрә сорау һәм биремнәрне ул укучыларның белемнәрне үзләштерү процессын ничек оештыруга карап классификацияли, аларны өч группага бүлә. Аларның беренчесе — белемнәрне ныгыту функциясен үтәүче сорау һәм биремнәр (өйрәнелгәнне сөйләү, факт, төшенчәләрне беренчел истә калдыру, күнекмәләр формалаштыру). Икенчесе — логик фикерләү методларына һәм иҗади эшләү тәҗрибәсенә ия булырга ярдәм итә торган сорау һәм биремнәр (анализлау, синтезлау, чагыштыру, гомумиләштерүгә ярдәм итәрдәй мөстәкыйль эшләр, бәя бирү, нәтиҗә ясау сыйфатлары формалаштыру). Өченчесе - алган белемнәрне иҗади куллануны таләп итә торган сорау һәм биремнәр (мөстәкыйль ишләрне үтәү, танып-белү эшчәнлегенең яңа шартларында белемне куллану күнекмәләренә ия булу). Бу классификация иң яхшы гуманитар дәреслекләр төзү практикасы һәм совет дидактикасы, психологиясе, проблемалы укыту теориясе казанышларын истә тотып эшләнгән.

Дәреслекләр төзү өлкәсендә иң алдынгы казанышларны гомумиләштереп һәм прогрессив тенденцияләргә таянып, автор мәктәп дәреслегенең педагогик нигезен бәян иткән. Бу хезмәт укыту эчтәлеге проблемаларын эшкәртүгә, мәктәп дәреслекләрен камилләштерү бурычын гамәлгә ашыруга булышачак.

**М. МӘХМҮТОВ,**

СССР Педагогия фәннәре академиясе академигы.